**Республика Татарстан**
**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

## Постановление

«25» август, 2018 ел № 1359

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 8 ноябрендәге 1661 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Питрәч районы капиталь төзелеш үзәге» муниципаль унитар предприятиесе Уставына үзгәрешләр кертү һәм аны яңа кушымтада бирелгән редакциядә раслау турында»

«Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 13.3 статьясы, «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы җирле үзидарә органына буйсынган оешма (учреждение) җитәкчесенең хәбәр итү тәртибе турында, вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү хакында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2018 елның 24 июлендәге 150 номерлы карарының 2.2 пункты нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 маендагы 1063-р номерлы күрсәтмәсе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 10 августындагы 2091-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә «Татарстан Республикасы Питрәч районының капиталь төзелеш үзәге» муниципаль унитар предприятиесе Уставын Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 8 ноябрендәге 1661 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Питрәч районының капиталь төзелеш үзәге» муниципаль унитар предприятиесе Уставына үзгәреш кертергә, аны кушымтада бирелгән яңа редакциядә расларга.

2. «Татарстан Республикасы Питрәч районы капиталь төзелеш үзәге» муниципаль унитар предприятиесе башлыгы Вафин М.М. Уставка билгеләнгән тәртиптә үзгәрешләр дәүләт теркәвен үткәргәндә мөрәҗәгать итүче булып чыгыш ясарга.

3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы сайтында әлеге карарны бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитетының җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Шәйхетдинов